| ГЛАВА<br>ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ ЛӘКЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 10 нчы ноябрь № 4

Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегендә 2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Ләке авылында халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгы КАРАР чыгарды:

1. 2025 елның 21 ноябрендә 14.00 сәгатькә Сарман муниципаль районы, Ләке авылы, Тау башы ур., 12 а йорт адресы буенча урнашкан Ләке мәдәният йорты бинасында 2026 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан; ялгыз өлкән гражданнар; көндезге формада белем алучы студентлар; ашыгыч хәрби хезмәт узучы гражданнар, контракт буенча хәрби хезмәт узучылар, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, үзара салым кертү турында һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме:

1. Ләке торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

2. Ләке торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, Тау башы урамындагы юлларга вак таш түшәү (махсус техниканы арендалау, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, вак таш ташу,юлга салу һәм тарату);

3. Җәйге чорда торак пункт территориясен төзекләндерү (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу;

4. Ләке торак пунктында урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (яктыртуның урам челтәрләрен ремонтлау (лампаларны, таймерларны, энергияне сак тотучы яктырткычларны сатып алу һәм урнаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5. Ләке торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын (паркларны, скверларны, яр буен, пляжларны, спорт мәйданчыкларын һәм халыкның күпләп ял итә торган башка урыннарны) төзү, ремонтлау һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү (шартнамә буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

"ӘЙЕ " " КАРШЫ?»

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең информацион стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы Ю.Г.Антонов

ОГРН 1021601313942 Совет Лякинского сельского поселения Ләке авыл җирлеге Советы ИНН 1636002534